КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 10 май г.Казань № 374

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында яңа коронавирус йогышлы авыруы таралуны булдырмау чаралары турында» 2020 ел, 19 март, 208 нче карарына үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасында санитар-эпидемиологик хәлне һәм яңа коронавирус йогышлы авыруы таралу үзенчәлекләрен исәпкә алып, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында яңа коронавирус йогышлы авыруы таралуны булдырмау чаралары турында» 2020 ел, 19 март, 208 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 ел, 25 март, 218 нче; 2020 ел, 27 март, 223 нче; 2020 ел, 30 март, 234 нче; 2020 ел, 31 март, 240 нчы; 2020 ел, 3 апрель, 252 нче; 2020 ел, 6 апрель, 260 нчы; 2020 ел, 10 апрель, 272 нче; 2020 ел, 13 апрель, 280 нче; 2020 ел, 18 апрель, 306 нчы; 2020 ел, 21 апрель, 313 нче; 2020 ел, 29 апрель, 349 нчы; 2020 ел, 30 апрель, 356 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып), аны яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян итеп, үзгәреш кертергә.

2. Бу карар 2020 елның 12 маеннан үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2020 ел, 19 март, 208 нче
карары
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2020 ел, 10 май, 374 нче
карары редакциясендә)

Татарстан Республикасында яңа коронавирус йогышлы авыруы таралуны булдырмау чаралары турында

Яңа коронавирус йогышлы авыруы таралу куркынычына бәйле рәвештә һәм «Халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау турында» 1994 елның 21 декабрендәге 68-ФЗ номерлы, «Халыкның санитар-эпидемиология иминлеге турында» 1999 елның 30 мартындагы 52-ФЗ номерлы федераль законнар, Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасының гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү буенча территориаль ярдәмче системасы идарәсе органнары һәм көчләре өчен югары әзерлек режимын кертү турында» 2020 елның 19 мартындаы 129 номерлы боерыгы нигезендә, шулай ук Россия Федерациясе территориясенә яңа коронавирус йогышлы авыруын кертүне һәм таратуны кисәтү буенча оператив штаб карарларын, Россия Федерациясенең баш дәүләт санитар табибы карарларын, Татарстан Республикасы буенча баш дәүләт санитар табибы тәкъдимнәрен (күрсәтмәләрен) тормышка ашыру максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Халыкның санитар-эпидемиология иминлеген тәэмин итүгә юнәлдерелгән чикләү һәм башка чаралар комплексын, шул исәптән аларны Татарстан Республикасының гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү буенча территориаль ярдәмче системасы идарәсе органнары һәм көчләре өчен югары әзерлек режимы шартларында тормышка ашыру Татарстан Республикасының бөтен территориясендә гамәлгә ашырыла дип билгеләргә.

2. Гражданнарга үз-үзеңне изоляцияләү режимын саклауны, кирәк булмаганда, яшәү (тору) урыныннан чыкмауны, башка гражданнар белән аралашуны максималь дәрәҗәдә чикләүне тәкъдим итәргә.

3. Гражданнарның турыдан-туры катнашында, шул исәптән паркларда, урман паркларында һәм скверларда, сәүдә һәм сәүдә-күңел ачу үзәкләрендә (комплексларында), аттракционнарда һәм гражданнар күпләп йөри торган башка урыннарда ял итү, күңел ачу, тамаша, мәдәни, физкультура, спорт, күргәзмә, агарту, реклама һәм башка шундый чаралар үткәрү рөхсәт ителми дип билгеләргә.

4. 2020 елның 26 мартыннан санитар-эпидемиологик хәл яхшырганга кадәр спорт үзәкләре, йөзү бассейннары, фитнес-үзәкләр, кинотеатрлар (кинозаллар), төнге клублар (дискотекалар), балалар уен бүлмәләре, балалар күңел ачу үзәкләре һәм башка күңел ачу оешмалары эшчәнлеген туктатырга.

5. 2020 елның 28 мартыннан санитар-эпидемиологик хәл яхшырганга кадәр түбәндәгеләрнең эшләвен туктатырга:

а) сәүдә, сәүдә-күңел ачу үзәкләре (комплекслары), ваклап сату базарларының (аларда урнашкан:

даруханәләрдән һәм даруханә пунктларыннан;

азык-төлек товарлары белән ваклап сәүдә итү объектларыннан;

тыштан (урамнан) аерым керү юлы булганда, мобиль элемтә хезмәтләре күрсәтүгә шартнамәләр төзү гамәлгә ашырыла торган объектлардан тыш);

б) башка ваклап сәүдә итү объектларының (түбәндәгеләрдән тыш:

даруханәләрдән, даруханә пунктларыннан;

азык-төлек товарлары белән ваклап сәүдә итү объектларыннан;

транспорт чаралары белән ваклап сәүдә итү объектларыннан;

тыштан (урамнан) аерым керү юлы булганда, килүчеләр өчен сәүдә залының файдалану мәйданы 400 кв.метрга кадәр булган азык-төлек булмаган башка товарлар белән ваклап сәүдә итү объектларыннан);

в) җәмәгать туклануы хезмәтләре күрсәтү объектларының (гражданнар, мондый объектлар урыннарында булмыйча, үзләре белән алуга хезмәт күрсәтүдән, заказлар илтүдән, тиешле оешмалар хезмәткәрләренә оешмалар урыннарында җәмәгать туклануы хезмәтләре күрсәтүдән, шулай ук кунакханәләрдә аларда яшәүче затларга җәмәгать туклануы хезмәтләре күрсәтүдән тыш);

г) мунчаларның, сауналарның.

Чикләүләр товарларны дистанцион ысул белән сатуга, товарларны илтүгә (Россия Федерациясе законнары белән ирекле сату булуы тыелмаган яки чикләнмәгән товарлардан тыш) карата кагылмый.

6. 2020 елның 28 мартыннан санитар-эпидемиологик хәл яхшырганга кадәр шифаханә-курорт оешмаларында (шифаханәләрдә), ел әйләнәсе эшли торган шифаханә-сәламәтләндерү балалар лагерьларында урыннар броньлауны, гражданнар (эш буенча командировкаларда яки эш буенча сәфәрләрдә булган затлардан тыш) кабул итүне һәм урнаштыруны туктатырга.

Бу пунктның беренче абзацында күрсәтелгән оешмаларга аларда урнаштырылган затларга карата:

аларның яшәү вакыты тәмамланганга кадәр, аны озайту мөмкинлегеннән башка, үз-үзләрен изоляцияләү өчен шартлар тудыруны һәм кирәкле санитар-эпидемиологик чаралар үткәрүне тәэмин итәргә;

аларның туклануын бу затлар яшәгән биналарда гына Кулланучылар хокукларын яклау һәм кеше иминлеген саклау өлкәсендә күзәтчелек итү федераль хезмәтенең аңлатмалары нигезендә оештырырга.

7. 2020 елның 6 апреленнән санитар-эпидемиологик хәл яхшырганга кадәр түбәндәгеләрнең эшчәнлеген туктатырга:

инвалидларны тернәкләндерү буенча дәүләт үзәкләренең;

сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән балалар һәм яшүсмерләр өчен

дәүләт тернәкләндерү үзәкләренең;

Татарстан Республикасының халыкка социаль хезмәт күрсәтү комплексլы үзәкләренә караган социаль-тернәкләндерү бүлекләренең;

Татарстан Республикасында социаль хезмәт күрсәтүләр белән тәэмин итүчеләр реестрына кертелгән, әмма дәүләт йөкләмәсен (заказын) үтәүдә катнашмый торган, инвалидларга, 65 яшьтән өлкәнрәк гражданнарга, инвалид балаларга тернәкләндерү хезмәтләре күрсәтүче дәүләткә карамаган социаль хезмәт күрсәтүләр белән тәэмин итүчеләрнең.

8. Санитар-эпидемиологик хәл яхшырганга кадәр түбәндәгеләрне тыярга:

2020 елның 19 мартыннан оешмалар һәм индивидуаль эшмәкәрләр тарафыннан үз карамагындагы объектларда һәм территорияләрдә тәмәке тарту өчен кальяннар бирү буенча хезмәтләр күрсәтүне, кальяннар куллануны;

2020 елның 1 апреленнән җиңел таксида берьюлы ике кешедән күбрәк пассажирлар (балигъ булмаган затларны исәпкә алмыйча) йөртүне;

2020 елның 13 апреленнән Татарстан Республикасы дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәкләрендә гариза бирүчеләрне кабул итүне (дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр порталы һәм дәүләт хакимияте органнарының һәм җирле үзидарә органнарының рәсми сайтлары аша электрон рәвештә хезмәтләр күрсәтүгә гаризалар бирү (соратып алулар) каралмаган хезмәт күрсәтүләргә карата билгеле бер көнгә һәм вакытка алдан язылу буенча кабул итүдән тыш);

2020 елның 14 апреленнән гражданнарның гыйбадәт кылу урыннарында, биналарында һәм корылмаларында, мондый биналар һәм корылмалар урнашкан җир кишәрлекләрендә булуын, шулай ук әлеге объектларда һәм территорияләрдә үткәрелә торган дини йолаларда һәм тантаналарда катнашуын (руханилар, шулай ук гыйбадәтләр кылуны башкару һәм әлеге объектларның эшләве өчен кирәк булган затлар катнашыннан тыш);

2020 елның 23 апреленнән ваклап сәүдә итү объектларының (даруханәләрдән, даруханә пунктларыннан һәм автомобильләргә ягулык салу станцияләреннән тыш) 22 сәгать 00 минуттан 6 сәгать 00 минутка кадәр эшләвен;

2020 елның 12 маеннан гражданнарның, сулыш органнарын шәхси саклау чараларын (битлекләр, респираторлар) кулланмыйча, ваклап сәүдә итү, хезмәтләр күрсәтү объектларына, пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашырганда транспорт чараларына (таксины кертеп) керүен һәм булуын, шулай ук гражданнарның җәмәгать урыннарында булуын;

2020 елның 12 маеннан гражданнарның, кулларны шәхси саклау чараларын (перчаткалар) кулланмыйча, ваклап сәүдә итү объектларына, пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашырганда транспорт чараларына (таксины кертеп) керүен һәм булуын;

2020 елның 12 маеннан гражданнарның балалар өчен уен мәйданчыкларында, балалар мәйданчыкларында, спорт мәйданчыкларында, шул исәптән күпфатирлы йортлар ишегалларында урнашкан мәйданчыкларда булуын. Бу тыю әлеге объектларга хезмәт күрсәтүче оешмалар хезмәткәрләренә кагылмый.

2020 елның 12 маеннан муниципалитетлар арасында пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны (даими йөртүләр маршрутлары буенча пассажирлар йөртүдән һәм багаж ташудан тыш);

2020 елның 12 маеннан катнашучыларның гомуми саны 10 кешедән артык булган никахлашуны дәүләт теркәвенә алуны.

9. Санитар-эпидемиологик хәл яхшырганга кадәр түбәндәгеләрне йөкләргә:

2020 елның 30 мартыннан гражданнарга җәмәгать урыннарында, ваклап сәүдә итү, хезмәтләр күрсәтү объектларында башка гражданнар белән ике арада кимендә 1,5 метр дистанция (социаль дистанция) саклауны;

2020 елның 12 маеннан оешмаларга, индивидуаль эшмәкәрләргә, шулай ук «Һөнәри керемгә салым» махсус салым режимын кулланучы гражданнарга бу карарга теркәлгән 1 нче кушымтада аларның эшчәнлеген оештыруга карата билгеләнгән таләпләрнең үтәлешен тәэмин итүне.

10. 2020 елның 23 апреленнән санитар-эпидемиологик хәл яхшырганга кадәр түбәндәге гражданнарга 14 календарь көн дәвамында өйдә үз-үзеңне изоляцияләүне тәэмин итүне йөкләргә:

Россия Федерациясе субъектлары территорияләреннән килгән (кайткан);

Россия Федерациясе субъектлары территорияләреннән килгән (кайткан) гражданнар белән изоляцияләүне тәэмин итү чорында бер яшәгән.

Сулыш юлларына караган беренче авыру симптомнары барлыкка килгәндә, бу пунктта күрсәтелгән затлар, медицина оешмаларына бармыйча, өйдә медицина ярдәме күрсәтүне сорап кичекмәстән мөрәҗәгать итәргә тиеш.

Бу пункт белән билгеләнгән чикләүләр түбәндәгеләргә кагылмый:

халыкара, төбәкара йөкләр ташуны, пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыручы затларга;

Татарстан Республикасыннан читтә яшәүче, шул исәптән вахта ысулы белән эшләүче оешмалар хезмәткәрләренә. Татарстан Республикасыннан читтә яшәүче хезмәткәрләрне дистанцион эшләү формасына күчерү мөмкинлеге булмаганда оешмаларга, бу карар белән билгеләнгән таләпләрнең үтәлешен тәэмин итеп, аларның эшләвен нигездә вахта ысулы белән һәм Татарстан Республикасы территориясендә бер урында тупланып аерым яшәвен оештырырга.

Татарстан Республикасыннан читтә теркәлгән, Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан оешмалар өчен эшләр башкару һәм хезмәтләр күрсәтү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмалар хезмәткәрләренә (бу карар белән билгеләнгән таләпләрнең үтәлешен тәэмин итеп, мондый хезмәткәрләрнең Татарстан Республикасы территориясендә бер урында тупланып аерым яшәвен оештыру шарты белән).

11. 2020 елның 14 апреленнән Татарстан Республикасына чит ил дәүләтләре территорияләреннән килгән (кайткан) барлык затларга карата алар килгән (кайткан) көннән 14 календарь көн дәвамында обсерватор шартларында аларны изоляцияләү һәм аларга медицина күзәтүе тәэмин ителә дип билгеләргә.

12. 65 яшьтән өлкәнрәк яки бу карарга теркәлгән 2 нче кушымтада күрсәтелгән авырулары булган гражданнарга яшәү (тору) урыннарыннан чыкмауны тәкъдим итәргә, түбәндәгеләрдән тыш:

ашыгыч (кичектергесез) медицина ярдәме күрсәтүне сорап мөрәҗәгать итүдән һәм гомеренә һәм сәламәтлегенә турыдан-туры башка куркыныч янаудан;

дистанцион эшләү формасына күчү мөмкинлеге булмаган очракта, эш урынына барудан һәм аннан кире кайтудан;

товарлар сатып алу, эшләр башкару, хезмәт күрсәтүләрнең якынрак урнашкан урынына барудан;

кешеләр күпләп йөри торган урыннарда булмыйча, яшәү (тору) урыныннан 100 метрдан артмаган ераклыкта урамда йөрүдән яки йорт хайваннарын урамда йөртүдән;

калдыкларны аларның иң якын урнашкан җыю урынына кадәр илтүдән;

дачага (шәһәр читендәге йортка) барудан яки дачадан (шәһәр читендәге йорттан) кайтудан.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2020 ел, 19 март, 208 нче
карарына 1 нче кушымта

Оешмалар, индивидуаль эшмәкәрләр,
шулай ук «Һөнәри керемгә салым» махсус салым режимын
кулланучы гражданнар эшчәнлеген оештыруга карата таләпләр

1. Оешмаларга, индивидуаль эшмәкәрләргә:

1) үз карамагындагы объектларда, территорияләрдә һәм транспорт чараларында хезмәткәрләрнең сулыш органнарын шәхси саклау чараларын (битлекләр, респираторлар) һәм, кирәк булганда, кулларны шәхси саклау чараларын (перчаткалар) куллануын тәэмин итәргә;

2) гамәлдәге санитар кагыйдәләрне һәм гигиена нормативларын, шулай ук федераль дәүләт санитария-эпидемиология күзәтчелеген гамәлгә ашыручы органның (вазыйфаи затның) күрсәтмәләрен һәм таләпләрен тайпылышсыз үтәүне тәэмин итәргә;

3) көн саен эш (смена) башланганга кадәр хезмәткәрләрнең тән температурасын үлчәргә һәм алардан сулыш юллары белән бәйле авыру симптомнары (томау, тамак төбе кымырҗау, ютәл) булу-булмавы турында сораштыру үткәрергә, шулай ук эш көне дәвамында эш урыннарында һәм (яки) эш бирүче территориясендә хезмәткәрләрнең тән температурасын алга таба дүрт сәгатькә кимендә бер тапкыр тәкъдим ителә торган вакыт аралыгы белән үлчәргә;

4) тән температурасы югары, йогышлы авыру билгеләре булган затларга эшләргә рөхсәт итмәскә;

5) бүлмәләрдә, вирусларны һәм микроорганизмнарны бетерә торган йогышсызландыру чараларын кулланып, гомуми кулланылыштагы урыннарны, җиһазны, инвентарьны, оештыру техникасын һәм өслекләрне дезинфекцияләүне гамәлгә ашырырга;

6) кешеләр була торган урыннардагы эш бүлмәләрен даими (һәр ике сәгать саен) җилләтергә;

7) гомуми бурычлар һәм җитештерү процесслары белән бәйле булмаган аерым цехлар, участоклар, бүлекләр һәм функциональ эш төркемнәре коллективлары арасында аралашуны, хезмәткәрләрнең төшке аш вакытында һәм ял вакытында хәрәкәт итүләрен, оешмага, индивидуаль эшмәкәргә караган территориядән читкә чыгуны, башка участокларга, хезмәт, эш вазыйфаларын үтәүгә бәйле булмаган бүлмәләргә, урыннарга баруны чикләргә;

8) кулларны тире антисептиклары белән эшкәртү мөмкинлеген тәэмин итәргә;

9) гомуми файдаланудагы урыннарда сулыш органнары белән бәйле кискен вируслы инфекцияләрне профилактикалау турында мәгълүмат урнаштырырга;

10) эш көне тәмамланганнан соң, вирусларны һәм микроорганизмнарны бетерә торган йогышсызландыру чараларын кулланып, бүлмәләрне юеш-дымлы чүпрәк белән җыештырырга;

11) Россия Федерациясе субъектлары территорияләреннән килгән (кайткан) хезмәткәрләргә килгән (кайткан) көннән 14 календарь көн эчендә (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында яңа коронавирус йогышлы авыруы таралуны булдырмау чаралары турында» 2020 елның 19 мартындагы 208 номерлы карары белән билгеләнгән очраклардан тыш) эшкә чыгарга рөхсәт итмәскә, аларга әлеге вакыт эчендә өйдә үз-үзеңне изоляцияләү режимын саклауны тәэмин итүдә булышлык күрсәтергә;

12) Кулланучылар хокукларын яклау һәм кеше иминлеген саклау өлкәсендә күзәтчелек итү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсеннән сорау кергәндә, коронавирус йогышлы авыруы белән авыручының хезмәт функцияләрен үтәүгә бәйле рәвештә булган барлык аралашкан кешеләре турында кичекмәстән мәгълүмат тапшырырга, әлеге авыручы булган эш урыннарын һәм бина урыннарын дезинфекцияләүне тәэмин итәргә;

13) хезмәткәрләр арасында коронавирус йогышлы авыруын профилактикалау буенча кирәкле чаралар күрергә;

14) корреспонденция кабул итүне һәм җибәрүне бары ведомствоара электрон документ әйләнеше системасы, электрон һәм почта элемтәсе аша гамәлгә ашырырга;

15) эшчәнлекне оештыру үзенчәлекләреннән чыгып, санитар-эпидемиология иминлеген тәэмин итү буенча башка чаралар күрергә;

16) вакансияләр булуга карап, алар турында урнашу урыны буенча халыкны эш белән тәэмин итү үзәкләренә мәгълүматлар бирергә.

2. Гражданнар белән хезмәттәшлек иткәндә оешмаларга һәм индивидуаль эшмәкәрләргә бу таләпләрнең 1 нче пунктында күрсәтелгән таләпләргә өстәмә рәвештә:

1) гражданнарның, сулыш органнарын шәхси саклау чараларын (битлекләр, респираторлар) кулланмыйча, ваклап сәүдә итү, хезмәтләр күрсәтү объектларына, пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашырганда транспорт чараларына (таксины кертеп) керүен һәм булуын рөхсәт итмәскә;

2) гражданнарның, кулларны шәхси саклау чараларын (перчаткалар) кулланмыйча, ваклап сәүдә итү объектларына, пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашырганда транспорт чараларына (таксины кертеп) керүен һәм булуын рөхсәт итмәскә;

3) сәүдә объектының сәүдә залында бер үк вакытта була алган затларның килүчеләр файдалана алган сәүдә залы мәйданының 4 кв.метрына бер кеше (хезмәткәрләрне кертеп) исәбеннән билгеләнә торган иң чик санын арттырырга рөхсәт итмәскә;

4) гражданнарны аларга хезмәтләр күрсәтү максаты белән кабул итүне алдан язылу буенча гамәлгә ашырырга, агымдагы дезинфекцияләүне үткәрү һәм җилләтү өчен бер кабул итү белән икенче кабул итү арасында кимендә 10 минут буш вакыт калдырырга;

5) хезмәткәрләрнең сулыш органнарын индивидуаль саклау чараларын (битлекләр, респираторлар) һәм кулларны индивидуаль саклау чараларын (перчаткаларны) мәҗбүри кулланууын тәэмин итәргә;

6) гражданнарның (хезмәткәрләрне кертеп) социаль дистанция саклавын, шул исәптән үз карамагындагы объектларда, территорияләрдә махсус тамга сызу һәм аларга гражданнарны (хезмәткәрләрне кертеп) социаль дистанция саклана торган санда кертү һәм булу режимын билгеләү юлы белән тәэмин итәргә;

7) гражданнарның кулларын тире антисептиклары белән эшкәртү мөмкинлеген тәэмин итәргә;

8) бүлмәләрдә гомуми кулланылыштагы урыннарны, җиһазны, инвентарьны, оештыру техникасын һәм өслекләрне дезинфекцияләүне, вирусларны һәм микроорганизмнарны бетерә торган йогышсызландыру чараларын кулланып, көненә кимендә өч тапкыр гамәлгә ашырырга;

3. Оешмаларга һәм индивидуаль эшмәкәрләргә түбәндәгеләр тәкъдим ителә:

эшне нигездә дистанцион формада оештыру;

хезмәткәрләрне дистанцион эшләү формасына күчергәндә, иң беренче чиратта, 65 яшьтән өлкәнрәк хезмәткәрләрнең һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында яңа коронавирус йогышлы авыруы таралуны булдырмау чаралары турында» 2020 ел, 19 март, 208 нче карарына теркәлгән 2 нче кушымтада күрсәтелгән авырулары булган гражданнарның санын минимальләштерү;

хезмәткәрләрнең чит затлар белән аралашуын чикләү максаты белән аларны эш урынына кадәр алып баруны һәм аннан алып кайтуны оештыру.

4. «Һөнәри керемгә салым» махсус салым режимын кулланучы гражданнар үз эшчәнлегенә кагылышлы өлештә бу таләпләрне үтиләр.

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2020 ел, 19 март, 208 нче
карарына 2 нче кушымта

Авырулар исемлеге

1. Эндокрин системасы авыруы – Авыруларның халыкара классификациясе – 10 (АХК-10) нигезендә Е10 диагнозы буенча классификацияләнә торган инсулинга бәйле шикәр авыруы.

2. Түбәндәгеләр арасыннан сулыш органнары авырулары:

2.1. Авыруларның халыкара классификациясе – 10 нигезендә J44 диагнозы буенча классификацияләнә торган башка хроник обструктив үпкә авыруы.

2.2. Авыруларның халыкара классификациясе – 10 нигезендә J45 диагнозы буенча классификацияләнә торган астма.

2.3. Авыруларның халыкара классификациясе – 10 нигезендә J47 диагнозы буенча классификацияләнә торган бронхоэктатик авыру.

3. Кан әйләнеше системасы авыруы – Авыруларның халыкара классификациясе – 10 нигезендә 127.2, 127.8, 127.9 диагнозлары буенча классификацияләнә торган үпкә авырулары аркасында йөрәк һәм үпкә кан әйләнеше бозылулары авыруы.

4. Авыруларның халыкара классификациясе – 10 нигезендә Z94 диагнозы буенча классификацияләнә торган трансплантацияләнгән органнар һәм тукымалар булу.

5. Сидек-җенес системасы авыруы – Авыруларның халыкара классификациясе – 10 нигезендә 18.0, 18.3 – 18.5 номерлы диагнозлар буенча классификацияләнә торган 3 – 5 стадияләрдәге хроник бөер авыруы.

6. Түбәндәгеләр арасыннан яман шеш авырулары*:

6.1. Авыруларның халыкара классификациясе – 10 нигезендә С00 – С80, С97 диагнозлары буенча классификацияләнә торган теләсә кайсы локализациядәге, шул исәптән күп санлы мөстәкыйль локализациядәге яман шеш авырулары.

6.2. Авыруларның халыкара классификациясе – 10 нигезендә С81 – С96, D46 диагнозлары буенча классификацияләнә торган кискен лейкозлар, югары дәрәҗәдәге яман шеш авырулы лимфомнар, башка лимфопролифератив авыруларның рецидивлары һәм резистент формалары, хроник акселерация һәм бласт кризы фазаларындагы хроник миелолейкоз, беренчел хроник лейкозлар һәм лимфомнар*.

---

* Өченче клиник төркемгә кертелгәннәрдән тыш (онкологиядә).

---